**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МҮЛМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк ур, 46а йорты

**СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма, ул.Центральная, д. 46а

Тел./факс: +7(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР**
21 июнь 2019 ел

**РЕШЕНИЕ**
№ 152

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. Мүлмә авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 декабрендәге 136 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта “бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар ширкәтләре” сүзләрен бетерергә;

2) 10 пунктны бетерергә.

2. Әлеге карарны ТР, Биектау муниципаль районы, Мүлмә авылы, Үзәк урам, 46а йорты адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендта, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Биектау муниципаль районы сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе урынбасары
авыл җирлеге башлыгы урынбасары — Р.Р. Гарафиев